СОВЕТ ЕЛАБУЖСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО
РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АЛАБУГА
МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОН СОВЕТЫ

РЕШЕНИЕ КАРАР

«01» ноябрь, 2024 ел Алабуга шәһәре № 393

**Алабуга муниципаль районы Советының «Социаль юнәлешле коммерциягә карамаган оешмаларга ярдәм итү турында» 2013 елның 28 августындагы 352 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Гамәлдәге законнарга туры туры китерү сәбәпле, Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Советы

КАБУЛ ИТТЕ:

1. Алабуга муниципаль районы Советының «Социаль юнәлешле коммерциягә карамаган оешмаларга ярдәм итү турында» 2013 елның 28 августындагы 352 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 6 пунктны түбәндәге редакциядәге 13-20 пунктчалар белән тулыландырырга:

«13) Ватанны саклаучыларның билгесез хәрби күмүләрен һәм күмелмәгән калдыкларын ачыклауга, һәлак булганнарның һәм Ватанны саклаганда хәбәрсез югалганнарның исемнәрен урнаштыруга юнәлдерелгән эзләү эше;

14) янгыннарны профилактикалауда һәм (яисә) сүндерүдә һәм һәлакәттән коткару эшләрен уздыруда катнашу;

15) мигрантларның социаль һәм мәдәни адаптациясе һәм интеграциясе;

16) наркотик чараларны яисә психотроп матдәләрне законсыз куллануны гамәлгә ашыручы затларны медицина реабилитациясе һәм социаль реабилитацияләү, социаль һәм хезмәт реинтеграциясе чаралары;

17) хезмәт ресурсларының мобильлеген арттыруга ярдәм итү;

18) сәяси репрессия корбаннарының хәтерен мәңгеләштерү;

19) муниципальара хезмәттәшлекне үстерү;

20) территорияне төзекләндерү.».

1.2. 6 пунктның 7 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«7) гражданнарның социаль куркыныч рәвешләрен профилактикалау, балигъ булмаганнарның күзәтүчесезлеген һәм хокук бозуларын профилактикалауда катнашу;».

2. Әлеге карар рәсми рәвештә бастырып чыгарылырга тиеш.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп контрольдә тотуны муниципаль корылыш һәм депутат этикасы мәсьәләләре буенча даими депутат комиссиясенә йөкләргә.

Комиссия рәисе урынбасары Р.Л. Исланов